## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ

Гражданнар җыенының 2022 елның 11 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Иске Смыловка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»

01 ноябрь 2023 ел №8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Иске Смыловка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 11 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» соравы буенча 2023 елның 01 сентябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, түбәндәге мәсьәләләрне карадылар:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Шуган авыл җирлегенең Иске Смыловка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 11 ноябрендәге 4 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы» 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«10. Торак пунктлар чикләрендә юл эшчәнлеге, шул исәптән отвал коммуналь гидроповоротлы КО-2,5м булдыру».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **12** кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **9** кеше, бу 75 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында **9** катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда **0** катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Иске Смыловка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең Иске Смыловка торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2022 елның 11 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Торак пунктлар чикләрендә юл эшчәнлеге, шул исәптән отвал коммуналь гидроповоротлы КО-2,5м булдыру».

3. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районының Шуган авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Шуган авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Басорина